Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге Советы

КАРАР №3

Уракчы ав. 2026 елның 6 нчы феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Советының 23.12.2025 елның 6 номерлы «Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына бюджеты турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Муниципаль норматив актны кануннарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Уракчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Балык Бистәсе муниципаль районының Уракчы авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Уракчы авыл җирлеге Советының «2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Уракчы авыл җирлеге бюджеты турында» 23.12.2025 №6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 статьясындагы 10 өлешенең 2 пунктында» сүзләрен «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясында» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы, Совет ур., 36А йорт; Мельничный Пүчинкәсе авылы, Киров ур., 20 Б адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Гәрәев